КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 6 сентябрь г.Казань № 794

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийларын раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 971 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийларына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлык категориясенә кертү критерийларын раслау турында» 2018 ел, 31 октябрь, 971 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә

ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү критерийларына, 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Юридик затларны, индивидуаль эшмәкәрләрне план буенча тикшерүләр, алар гамәлгә ашыра торган эшчәнлеккә критерийлар нигезендә бирелгән риск категориясеннән чыгып, түбәндәге эзлеклелектә үткәрелә:

югары рисктагы категория өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый рисктагы категория өчен – өч елга бер тапкыр;

уртача рисктагы категория өчен – алты елга бер тапкырдан ешрак һәм сигез елга бер тапкырдан кимрәк түгел;

түбән рисктагы категория өчен тикшерүләр үткәрелми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин